«Пешекче ул – артист та, табиб та»

Атаклы аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның тууына 90 ел тулуга багышлап, «Казан» ипподромында халыкара кулинария бәйгесе уза. Анда аш-су пешерүчеләр милли ризыкларны әзерләү буенча һөнәри осталыкта ярыша.

5 БИТ

Батырлык хакына

Казанның 113нче мәктәбендә Россия герое Марат Әхмәтшин истәлегенә мемориаль такта һәм стенд экспозициясе ачылды, шулай ук мәктәпкә аның исеме бирелү уңаеннан зур чара булды.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 28.02.2017 | №20 (5782)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ЯЗ: КЕМГӘ – СӨЕНЕЧ, КЕМГӘ – СУ БАСУ

Казанда су басу ихтималы булган урыннар исемлеге **www.shahrikazan.com** сайтында

Казанда язгы ташулар 29 марттан 12 апрельгә кадәр дәвам итәр дип көтелә. Кар катламы уртача – 65, ә туң катламы 57 сантиметр. Иң проблемалы участоклар дип Салмачы һәм Вишневка бистәләре санала.

Авторның фотоархивыннан

Дамир БӘДРИЕВ

– Казандагы карда һәм бозда 52 миллион тонна су тупланган. Туң катламы шактый тирән, шунлыктан су җиргә сеңә алмаячак. Һава кискен җылыткан очракта, 13 квадрат километр мәйданны су басу ихтималы бар. Әлеге хәвефле мәйдан 386 торак йортны уз эченә ала. Биредә 1223 кеше яши, – диде шәһәрнең гражданнарны яклау идарәсе җитәкчесе Фердинант Тимурханов.

– Иделдә һәм Казансуда су биеклегенең критик чиге Балтыйк үлчәм системасы буенча 54 метр. Биеклек бу чикне узса, үзәнлектәге урыннарны су баса башлый. Нокса, Вертлевка, Коры елга, Киндерка елгалары шулай ук куркыныч. Константиновка бистәсендә Заречная урамы буенча Вертлевка елгасы аша салынган күпер авария хәлендә. Шәхси йортларда яшәүчеләр кар сулары агу өчен ерганакларны алдан ук казып куйсыннар иде. Казан метросы су басуларга каршы ныклы әзерлек чаралары башкарган, шуңа күрә метрода су басу булырга тиеш түгел.

Ташу вакытында эшләү өчен 790 кешедән торган авария бригадалары булдырылган, 154 берәмлек техника әзерләнгән. Әмма зур судан коткаручылар гына да йөзлп кала алмас. Шәһәрнең иң проблемалы участокларында коммуналь хуҗалык, юл хезмәте һәм җирле хакимиятнең дә ярдәме сорала. Әйтик, Яңа Савин районында Кемеров урамы иңкүлектә булганлыктан, анда суны даими суыртып торырга кирәк булачак. Киров районында исә коткаручыларны шәхси йортлар территориясе борчып тора.

Коткаручылар хәзердән үк тәүлек буе эшләүгә күчкән. Насос станцияләрен, җир асты кичүләрен тикшереп торалар, кирәкле җиһазларны барлыйлар. Идарәче компанияләр 3090 капчык ком һәм 795 трап әзерләп куйган. Бер үк вакытта балыкчылар белән дә профилактика эшләре башланган. Узган ел яз көне профилактика эшләре нәтиҗәсе буларак, сулыкларда балыкчылар белән бәхетсезлек очраклары күзәтелмәгән. Елгаларны боз кисәкләреннән һәм башка чүп-чардан арындыру өчен, шәһәр ярты миллион сум акча бүлеп биргән. Нокса һәм Киндерка елгасында инде эш башланган.

Гадәттән тыш эшләр министрлыгы хәбәр итүенчә, Чаллыда плотинага, Чулман елгасының түбәнге бьефына су басу куркынычы яный. Шулай ук Алабуга районының Тарловка бистәсе янындагы корылмаларның су астында калуы ихтимал. Түбән Кама районындагы Березовая Грива авылы халкына да су басуларга каршы ныклы әзерлектә тору кирәк булачак. Чөнки бу зонада шулай ук су басу куркынычы бар. Зәй сусаклагычында да кар суларына каршы ныклы әзерлек чаралары күрелгән. Хәвефле исемлектә Яшел Үзән районы да бар – Идел суы шәһәр дамбасында яшелүзәнлеләргә көтелмәгән афәтләр китереп чыгарырга мөмкин.

БЕЛЕП ТОР!

Су басу ихтималы булган йортларда азык-төлекне базлардан өскә чыгарыгыз; документларыгызны су үтми торган пакетларга салыгыз; кирәкле даруларны алдан хәстәрләгез; йортны вакытлыча калдырырга туры килгәндә газларны, электр утын, мичне сүндерегез.

Казан мэриясе рәсми порталының Гражданнарны яклау идарәсе битендә су басу шартларында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында мәгълүмат-белешмә урнаштырылган.

Гражданнарны яклау идарәсенең дежур телефоны: 264-29-00.

нәтиҗә

Рөстәм Миңнеханов артыгын мактанмаска чакырды

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан шәһәр Думасының XII сессиясендә Казан мэрының һәм шәһәр Башкарма комитетының узган елдагы эшчәнлекләрен уңай бәяләде. Ләкин: «Без – иң алдынгылар, дип уйласагыз, нык ялгышасыз», – дип искәртеп тә куйды.

Дамир БӘДРИЕВ

tatarstan.ru

Мэр Илсур Метшинның хисап докладында әйтелгәнчә, узган елда Казанда тулаем территориаль продукт 632 миллиард сумны тәшкил иткән. Икътисадка 174 миллиард сум инвестиция кертелгән. Башкалада уртача хезмәт хакы – 37,8 мең сум. Мәшгульлек үзәкләрендә 4426 кеше эшсез сыйфатында рәсми рәвештә теркәлгән, шул ук вакытта Казанда 14 мең вакансия бар.

Узган ел күпфатирлы 165 торак йорт капиталь төзекләндерелгән.

– Ишегалларын һәм йортара юлларны төзекләндерүдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның ярдәме зур. Бу максатларга республика бюджетыннан ел саен 500 миллион сум бирелә. Алты елда шәһәр ишегалларының 48 проценты төзекләндерелде, – дип әйтеп үтте Илсур Метшин.

Президент, әлеге уңайдан фикерләре белән уртаклашып: «Берьюлы бөтен ишегалларын да башкарып чыгып булмый. Төзекләндергәндә асфальт түшәү белән генә чикләнмичә, кешеләргә җыелышып утыру урыннары, ял, спорт мәйданчыклары да ясарга кирәк», – диде.

Казанда 2020 елда беренче сыйныфларга киләчәк балалар саны кискен рәвештә 20 процентка артачак.

– Республика күләмендә караганда, Казан – балалар икенче сменада укучылар саны буенча иң күп булган шәһәр. Хәзер мәктәпләр кытлыгы җитди мәсьәләгә әверелде, – диде Илсур Метшин. – Ике мәктәп төзелә, тагын ике мәктәп төзүгә керешеләчәк.

Павлюхин сайлау округыннан депутат Руслан Минабетдинов Казанда балалар спорт тренерларының хезмәт хаклары аз булуына игътибар юнәлтте. Аның әйтүенчә, Уфада – 25 мең сум, Ульяновскида – 23 мең сум, Екатеринбургта 39 мең сум алалар. Казанда 10-19 мең сум гына. Мэр Илсур Метшин әлеге мәсьәләдә күршеләрнең тәҗрибәсе өйрәнеләчәген әйтте.

– Республика башкаласында күп эшләр башкарыла, – диде Президент Рөстәм Миңнеханов. – Гомумән алганда, бүген без башкарган эшләр республиканың зур икътисади мөмкинлеккә ия булуына бәйле. Узган ел тулаем төбәк продукты 1 триллион 944 миллиард сум тәшкил иткән иде. Федерация күләмендәге күп кенә проектлар туктап калды. Татарстанда, шул исәптән Казанда проектларны гамәлгә ашыру дәвам итә. Бакчачылык ширкәтләренә теләктәшлек буенча яңа программа булдырдык.

Президент аңлатканча, бу – Казан һәм башка шәһәрләр өчен дә мөһим, чөнки татарстанлылар җәйләрен бакчачылык белән актив шөгыльләнә. Бакчачылык ширкәтләренә асфальт юллар салу башланачак. Дәваханәләр җитмәвен искәртеп, Президент бу юнәлештә дә программа башларга ышандырды.

– Казан матурланды, безгә туристлар күп килә. Туристлык кызыксындыручанлыгы, транспорт, логистика, иминлек турында уйланырга кирәк. Тулаем нәтиҗәләр уңай, күп эшләр башкарылды. Халык тагын да күбрәкне көтә. Күбрәк эшләгән саен, тизлекне дә арттыру зарур, – диде Президент Рөстәм Миңнеханов һәм искәртү дә ясады: – Әгәр сез үзегезне иң алдынгылар – кәттәләр, дип уйласагыз, нык ялгышасыз. Казан – башкала, тик көндәшлеккә әзер булу кирәк.

Кичә Сочида Россия инвестиция форумы башланды. Ике көнлек эш программасында Татарстанга кагылышлы чаралар да бар. Форумда Россия премьер-министры Дмитрий Медведев катнаша, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та чыгыш ясар дип көтелә.

Сочида кызу көннәр

Сочига бу көннәрдә Россия һәм чит илдәге зур компания җитәкчеләре, губернаторлар, фәнни һәм эшлекле даирә вәкилләре җыелды. Форумның беренче көнендә илнең икътисады, Россиянең эшлекле партнерлары белән элемтә турында сөйләштеләр. Эшсезлек, хезмәт хакы темасына да кагылдылар. Дмитрий Медведев әйтүенчә, илдә хезмәт базарында хәл тотрыклы. «Эшсезлекне җиңә алдык», – ди премьер-министр. Россия хөкүмәте рәисе урынбасары Ольга Голодец исә бу фикер белән килешсә дә, Россиядә эшчеләрнең хезмәте тиешенчә бәяләнмәвенә борчыла. «Россиядә 4,9 миллион кеше яшәү минимумы белән бер дәрәҗәдә хезмәт хакы ала», – ди ул.

Татарстан өчен мөһим яңалыкларның берсе – быелдан Россиянең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, санитария авиациясен «Ансат» һәм МИ-8 вертолетлары белән тәэмин итү проектын башлап җибәрәчәк.

– Россиядә үзенчәлекле климат һәм катлаулы географияле 34нәп төбәк санала. Вертолетларның үзебездә җитештерелүе – үзәктән читтә урнашкан территорияләргә үтеп керү өчен нәтиҗәле, – диде Россия сәламәтлек саклау министры Вероника Скворцова.

«Россия терәге» урта һәм кече эшмәкәрлеге иҗтимагый оешмасының вице-президенты Марина Блудян, «Газпромбанк» оешмасы вице-президенты Олег Костин, Россиянең икътисад үсеше министры урынбасары Олег Фомичев белән беррәттән Президент Рөстәм Миңнеханов та бүген «Сәнәгать кластерлары: региональ аспект» секциясендә чыгыш ясаячак.

Бирегә үзебезнең оешмаларның көндәшлеккә сәләте, сәнәгать кластерларының төбәк икътисады үсешенә йогынтысы, тәҗрибә турында фикер алышачаклар.

Татарстан белән кайбер чит төбәкләр арасында сәүдә-икътисад өлкәсендәге хезмәттәшлек турында килешүләр имзаланыр дип көтелә. Бүген форум барышында WorldSkills Kazan-2019 чемпионатына илче дә сайланачак.

«ТФБ Финанс» клиентларына ярдәм

«Татфондбанк»ның санацияләнүе турында әлегә төгәл берни билгеле булмаса да, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов мөрәҗәгать иткәч, «ТАИФ» компанияләр төркеме һәм партнерлары «Татфондбанк»ны торгызу эшендә катнашырга әзер булуларын белдерделәр.

Рөстәм Миңнеханов физик һәм юридик затларга хокукый ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнгән Консультатив төркемгә, шулай ук Татарстан Прокуратурасына, «ТФБ Финанс» клиентларын «Татфондбанк»тан зыян күргән кертемчеләр реестрына кертүне сорап, суд органнарына мөрәҗәгать әзерләргә йөкләде. Бу – операция эшчәнлеген туктаткан банк клиентларына ярдәм йөзеннән эшләнелә.

«Банктан зыян күргән клиентлар «Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы»ннан кертемнәрен кайтара алсын өчен, «ТФБ Финанс» клиентларын «Татфондбанк»ның зыян күргән кертемчеләре реестрына кертү мөһим. Бу хакта судка мөрәҗәгать әзерләнә. Нәтиҗәдә, «ТФБ Финанс» клиентлары хокукларын дәүләт иминиятләштергән кертемчеләр хокуклары белән тигезләштерү карала. Кертемнәрне клиентларга түләү «Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы» (АСВ) дәүләт корпорациясенә йөкләнгән», – дип хәбәр итә Татарстанның Икътисад министрлыгы матбугат хезмәте.

Рөстәм Миңнеханов исә «ТФБ Финанс» клиентларын яклау өчен юридик һәм хокукый мөмкинлекләр табарга кушкан. Искәртеп узабыз, клиентлар әйтүенчә, «Татфондбанк»та 1 миллион сумнан артыграк кертемнәре булганнарга июнь аеннан октябрьгә кадәр акчаларын банкның бүлендеге булып исәпләнгән «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенә күчерергә кушканнар. Әмма кертемнәрнең иминиятләштерелмәячәген алардан яшергәннәр. Нәтиҗәдә, еллык ставканың шактый югары процентларына кызыгып, күпләр «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенә күчкән. Тикшерү барышында «ТФБ Финанс»ка карата «Аеруча зур күләмдә алдау» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылды. Исәпләүләр буенча, кертемчеләргә килгән зыян күләме 90 миллион сумнан артык.

Татарстанның Сәүдә-сәнәгать палатасында эш көннәрендә 10:00дән 16:00 сәгатькә кадәр эшчәнлеген туктаткан банк клиентларына кеше хокуклары буенча консультатив төркем ярдәм күрсәтә. Шулай ук **(843) 524-90-90** «кайнар элемтә» номерына шалтыратып, борчыган сорауларга җавап та алырга мөмкин.

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Коралга кызыкмагыз

Татарстанда рөхсәт документы булган кешеләрдә 71 177 утлы корал исәпләнә.

Автор фотосы

Утлы коралны митингларга, спорт чараларына алып килү катгый тыела.

– Кеше, утлы коралын саклау өчен, ышанычлы шартлар булдырырга тиеш. Утлы коралны чит кешеләр, шулай ук гаилә әгъзалары кулланырлык булмасын. Тимер шкафның ачкычы да яшерелсен, – дип искәртте Росгвардия идарәсенең лицензия-рөхсәт эшләре үзәге җитәкчесе вазифаларын вакытлыча башкаручы Камил Абдразаков.

Автомобиль салонында утлы корал калдырырга ярамый. Узган ел автомобиль эченнән мылтык урлауның ике очрагы теркәлгән. Утлы коралны саклауга битарафлык күрсәткән өчен административ чаралар билгеләнгән. Урланган корал кеше үлеменә сәбәпче булса, җинаять эше дә кузгатыла. 100 мең сум штраф салына яки алты ай дәвамында хезмәт хакы тотып калына. Алты айга яки бер елга кадәр иректән мәхрүм калырга да мөмкин.

– Утлы коралларын саклауны тиешенчә оештырмаганнары өчен узган ел 3008 кешедән штраф түләттерелде, 3709 утлы корал гомумән дә тартып алынды, – диде Камил Абдразаков. – Узган ел кешеләр 3110 берәмлек утлы коралларын үзләре тапшырды. Моның өчен полиция бүлекчәләренә яки Росгвардиягә шалтыратырга кирәк. Коралны үзебез барып алабыз. Ирекле рәвештә корал тапшырган өчен акча да бирелә хәтта.

Акчалата бүләкләү түбәндәге тәртиптә: сырлы көпшәле утлы коралга – 3 мең сум, шартлаткыч матдәләргә – 2 мең сум, сугышчан граната һәм шома көпшәле ау мылтыгы өчен – 1500 сум, киселгән көпшәле мылтык һәм үзлектән ясалган утлы корал өчен – 1 мең сум, чикләнгән авырлыктагы һәлакәт тудыручы һәм газ коралы өчен – 500 сум, сырлы көпшәле утлы коралга сугышчан кирәк-яраклар өчен 20 сум.

– Кеше утлы коралын яшәү буенча теркәлгән җирендә генә сакларга тиеш. Әгәр яшәү урынын алыштырса, ул бу турыда лицензия-рөхсәт эшләре үзәгенә 14 көн эчендә хәбәр итәргә бурычлы. Таләп үтәлмәсә, 2 мең сум штраф салына, утлы коралны саклау һәм йөртү хокукы ике елга кадәр чикләнә, – диде Росгвардия идарәсенең лицензия-рөхсәт эшләре үзәге бүлек җитәкчесе Сергей Ратушный.

Камил Абдразаков утлы коралга кызыкмаска киңәш итте. «Утлы корал алу – үзеңә зур җаваплылык алу дигән сүз», – диде ул.

Дамир БӘДРИЕВ.

Биеклектә

Казанда «Биеклек-2017» республика конкурсына йомгак ясалды.

Дамир Бәдриев фотосы

– Иртән эш урынына чыгып киткән кеше кич гаиләсенә исән-имин кайтырга тиеш. Эш урыннарында, хезмәт иминлеген ныгыту максатында, «Биеклек» дигән конкурс башлап җибәрдек. Бәйге республиканыкы гына булса да, анда Мәскәү һәм Чиләбе командалары да катнашты. Аны бөтенроссия дәрәҗәсенә күтәрергә ниятлибез. Россиянең барлык төбәкләреннән командалар рәхим итеп Казанга килсеннәр! – диде хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары Марат Гафаров.

Татарстанда узган ел сәнәгатьнең төрле тармакларында хезмәт эшчәнлеге вакытында 45 кеше фаҗигале төстә һәлак булган.

– Төзелештә югары катларда, түбәләрдә һәм багана башларында эшләгәндә, иминлек кагыйдәләрен катгый үтәргә кирәк. Биеклек эшләүчеләрнең шушылай җыелышып ярышулары, чын мәгънәсендә, тәҗрибә-өйрәнү мәктәбе, – диде Марат Гафаров.

Республиканың «Төбәк укыту-методика үзәге» өстәмә сәнәгать белеме бирү учреждениесе директоры Рәисә Бабаназарова аңлатканча, командалар «арканга эленеп эшләү» һәм «арканга эләктерелеп эшләү» шартларында ярышкан. Арканга эленеп эшләгәндә, эшче-белгеч тулысынча һавада асылынып тора. Бу сиңа таганда атыну кебек рәхәтләнү түгел. Егетләр арканга эленгән рәвештә эш башкарды һәм тере кешене дә, маникенны да «коткарып» күрсәтте. Арканга эләктерелеп эшләгән очракта, эшче-белгеч аякларында яссылыкка басып йөри, бу – йорт, бина, поезд түбәсе.

– Түбәдә эшләүче кешенең биленә бәйләнгән арканның икенче очы ышанычлы сыйфатта ныклы әйбергә-терәккә беркетелергә тиеш. Икенче кешенең аркан очын куллары белән генә тотып торуы катгый тыела. Кинәт түбәнгә «очкан» кешене куллар белән тотып калып булмый, – ди Рәисә Бабаназарова.

«Арканга эленеп эшләү» бәйгесендә Татарстан Республикасы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Казан эзләү-коткару отряды җиңү яулады. Мәскәүнең «Аландр» командасы – икенче, «Инностейдж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять вәкилләре – өченче.

«Арканга эләктерелеп эшләү» бәйгесендә «Аландр» командасы лаеклы җиңү яулады. Калган призлы урыннарда җирле командалар: «Спецэнергомонтаж» оешмасы – икенче, «Казан» халыкара аэропорты – өченче урында.

Татарстан тәҗрибәсе үрнәк

Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте Россия Динара советы составына керде. Әлеге мөһим яңалыкны журналистларга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җиткерде.

– Россия Динара советы 1998 елда оешкан, ул үзенә православие, ислам, яхүд, будда конфессияләренең рухи лидерларын һәм вәкилләрен туплый. Оешма белән бөтен Россия һәм Мәскәү Патриархы Кирилл җитәкчелек итә. Совет Президиумы составына Мәскәү Патриархаты, Төньяк Кавказ мөселманнары координацион үзәге, Россия мөфтиләр шурасы, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте, Россия яхүдләре җәмгыяте федерациясе, Яхүд дини оешмалары һәм берлекләре конгрессы, Россия традицион будда җәмгыяте керә. Оешманың максаты – этникара конфликтлар, экстремизмны булдырмау, динара диалоглар кору, традицион рухи кыйммәтләрне пропагандалау, үзара тынычлыкка ирешү юлларын эзләү. Динара советка федераль дәрәҗәдәге үзәкләшкән оешмалар гына керә. Әмма Татарстан Мөселманнары диния нәзарәтенең киңкырлы эшчәнлеге, дини институтлар белән дәүләт арасында, шулай ук төрле конфессияара диалог кору тәҗрибәсе үрнәк булып торганга, безне дә совет составына керттеләр. Бу – бик зур дәрәҗә. Татарстан тәҗрибәсе башкалар өчен дә кызыклы булачак. Шул ук вакытта без үзебез дә күп нәрсәләргә өйрәнербез дип торабыз, – дип сөйләде мөфти Камил хәзрәт матбугат очрашуында.

Мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров сүзләренчә, республика динара татулыкны саклауда үрнәк булып тора. Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте динара татулыкны саклауга үз өлешен кертеп килә һәм аның бу өлкәдә башкарган эшләре бихисап.

– Димәк, безнең эшчәнлекне федераль дәрәҗәдә күрә, бәяли беләләр. Нәзарәтнең Россия динара совет составына керүе безнең өчен бик мөһим. Әлеге җитди мәйданчыкта Татарстан мөселманнары фикере да ишетеләчәк, – диде Рөстәм хәзрәт Батров.

Камил хәзрәт Динара советның әлегә кадәр эшләгән эшләре белән дә таныштырды.

– Совет комарлы уеннарны тыярга, югары аттестация комиссиясе исемлегенә теология фәнен кертергә, Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнен булдырырга чакырды, наркотикларга каршы көрәшү, миграция мәсьәләләре, мәктәпләрдә дини фәннәр укыту тәкъдимнәре белән чыкты, – диде Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Марат Әхмәтшин, соңгы сулышын алганда:

«Хатынымны һәм балаларымны яратам», – дигән

БАТЫРЛЫК

Узган елның декабрендә газетабызда «Йомык күздән дә яшь тама икән» дигән язма дөнья күрде. Анда без Сүриядә батырларча һәлак булган Марат Әхмәтшинның хатыны Гүзәл белән аның турындагы якты истәлекләрне барлаган идек. Казанның 113нче мәктәбендә Россия герое истәлегенә (капитан Марат нәкъ менә шушы мәктәптә укыган. – Авт.) мемориаль такта һәм стенд экспозициясе ачылу, шулай ук мәктәпкә аның исеме бирелү уңаеннан зур чара булды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Вакыт дәвалый, диләр. Мин бу сүзләр белән килешмим. Балаларымның әтисен, өзелеп яраткан иремне югалтканга тугыз ай үтте, әмма безнең гаиләгә килгән кайгының яралары тирәнәя генә, көннәр, айлар узган саен, моның мәңгелеккә икәнлеген аңлыйсың. Аеруча балалар әтиләрен бик сагына. Хәзер мин аларга әни дә, әти дә. Балаларымның хәтерендә аның белән бәйле истәлекләрнең мәңге саклануын, аларның да әтиләренә охшауларын телим. Кызганыч, соңгы вакытта миңа, еш кына: «Ни өчен ул чит илдә ятып калган? Ни мәгънә соң?» – дигән фикерләр ишетергә һәм укырга туры килде. Мин аларның барысына да: «Ул безнең һәм Россиядә яшәүче башка балаларның тыныч киләчәге өчен һәлак булды», – дип җавап бирәм. Терроризм әллә кайда еракта, бу безгә кагылмый, дип уйлыйбыз. Әмма ул кешеләр безнең янәшәбездә үк йөрергә мөмкин. Марат исә намусы кушканча эшләде, – диде геройның хатыны Гүзәл Әхмәтшина, күз яшьләре аша.

Герой исеменә лаеклы батырлык кылынганлыгы хәбәр ителсә дә, бүгенгә кадәр аның эшчәнлеге билгеле түгел иде. Шушы көннәрдә Гүзәл ханым иренең башка көрәшләрдә бергә булган хәрби иптәшеннән хат алган. Анда әлеге хәлнең ничек килеп чыгуы турында да әйтелә. Мәктәптә узган чарада батырның хатыны шушы хаттан өзек тә укыды.

«Безнең барыбыз өчен дә Марат чын офицер булды, – дип язылган анда. – Гаделлек, батырлык, яхшылык үрнәге иде. Май ахыры-июнь башында аның батареясы Пальмира шәһәре янында хезмәт итте. Марат һәрвакыт шәхси состав турында борчылды һәм иң авыр участокларда алдан йөрде. Нидер сизенгән кебек, ул һәрвакыт бронежилет кия иде. 1 июньдә батальонны Пальмирага җибәрү турында приказ алынды. Миңа сөйләүләре буенча, Марат һәм аның көрәшчеләре обронa тота. Бервакыт бөтен ату көче Марат ягына төбәлә. Аңа якын килү юллары киселгәнлектән, егетләр дә ярдәм итә алмый. Бик нык яралануга карамастан, ул көрәшүен дәвам итә. Инде соңгы сулышларын алган минутларда, дошманнар аның кем икәнлеген белмәсеннәр, гаиләсенә зыян салмасыннар өчен, куен кесәсендә йөрткән хатынының фотосын һәм үзенең документларын ерта. Шуннан соң ул кулына граната ала һәм: «Хатыныма, балаларыма әйтегез: мин аларны бик нык яратам!» – дип әйтә, үзен һәм дошманнарын шартлатыр өчен, аларның якынрак килүен көтә башлый. Әмма шул вакытта ярдәм килеп җитә һәм Маратны госпитальгә алып китәләр. Бик нык яраланган булуына карамастан, ахырга кадәр көрәшеп, кул астындагыларның берсен дә югалтмыйча, чын батырларча һәлак була ул...»

Мемориаль такта ачу чарасында да батырның балалары, әти-әнисе, туганнары-якыннары белән бергә Татарстанның хәрби комиссары Сергей Погодин, Казанның Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары башлыгы Тимур Алибаев та бар иде.

– Без бүген Марат Әхмәтшинны искә алабыз. Ул, илебезгә террорчылар килеп җитмәсен өчен, көрәшеп һәлак булды. Гомере бик кыска булса да, якты иде. Әйе, бу – безнең эшебез, хезмәтебез. Безгә шулай язылган. Ул да үз бурычын намус белән үтәде. Без аның батырлыгын бервакытта да онытмаячакбыз. Гаиләсенә, балаларына һәрчак ярдәм итәчәкбез. Хәрби пунктлардан безнең егетләр Марат Радиковичның батырлыгы турында белеп китә, – диде Сергей Погодин.

Геройның әтисе, үзе дә хәрби кеше Радик Әхмәтшин:

– Улыбызның исемен мәңгеләштерүдә үз өлешләрен керткән кешеләргә зур рәхмәт. Без шундый ул үстерүебез, аның Россия офицерының намусына тап төшермәве белән горурланабыз, – диде.

Сыртлановалар Сабада үсә

Ватаныңны ярату – патриотизм хисен яшьтән тәрбияләгәндә генә көтелгән нәтиҗәләргә, зур уңышларга ирешеп була. Шул темага багышланган мабугат конференциясендә Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов моны кат-кат ассызыклады. Патриотик аңны үстерергә булыша торган төрле иҗтимагый оешма җитәкчеләре, Саба кадетлар мәктәбе курсанты чыгыш ясады.

– Балаларыбыз, яшьләребез үз Ватаннарын яратсын өчен, без барысын да эшләргә тырышабыз, – диде министр. – Патриотик тәрбия бирүдә Татарстан – илдә алдынгы рәттә. Егетләрне армиягә чакыру кампаниясендә менә алтынчы ел инде беренчелекне бирәүгә дә бирмибез. Моңа, билгеле, яшьләр белән зур эш алып бару нәтиҗәсендә генә ирешеп була.

Патриотик тәрбия эшенең төп өлешен «Патриот» үзәге башкара. Ул, 57 хәрби-патриотик клуб белән бергә, армиягә каралыр яшькә җиткән егетләрне физик һәм рухи яктан чыныккан солдатлар булырга әзерли. Мондый киракле эштә республикабызның кадет мәктәпләре дә алдынгы рольне уйный. Саба кадетлар мәктәбенең 10нчы сыйныф укучысы, Казан кызы Луара Әхмәтова үз чыгышында шуны ассызыклады:

– Без, Саба кадетлар мәктәбеннән бер төркем егетләр һәм кызлар, 2016 елда Волгоградта узган Бөтенроссия «Җиңү» уены ярышларында катнаштык. Кыз кеше буларак, миңа автоматны сүтеп җыю шактый кыенга туры килде. Шулай да сынатмадым: кайбер егетләрдән тизрәк тә җыйганымны белгәч, үзем дә гаҗәпләндем. Бергәләп тырышканга, безнең Татарстан командасы бишенче призлы урынны алды, – дип шатланып сөйләде кыз.

Ә менә Татарстан турындагы чыгышлары икенче урынны алган. Мамаев курганны күрү дә бик тәэсирле булып, күңелләрендә кереп калган. Луара үзенең хәрби очучы буласы килү хыялын да яшермәде. Киләчәкнең Мәгубә Сыртлановасын зал алкышларга күмде.

«Ватан» берләшмәсе активисты Диләрә Гарипова, оешма тарафыннан алып барылган эзләнү эшләренә тукталып, болай диде:

– Без узган ел гына Ленинград өлкәсе һәм Белоруссиянең каты сугышлар барган җирләрендәге эзләнүләрдә 636 сугышчының җәсәден табып алып, хөрмәтләп җирләдек, сигезенең исемнәрен билгеле алдык.

Алар анда 15 регионнан килгән эзләнүчеләрне укытканнар. Быел 27 февраль көнне студентларның эзләнү отряды вәкилләре Казанга үзләренең беренче слетларына җыелды. «Нишләп Казанга?» дигән сорау урынсыз, чөнки бу эшне Казан Федераль университетының «Кар десанты», илдә беренчеләрдән булып, 1968 елда ук башлап җибәргән иде.

«Җиңү волонтерлары» оешмасы җитәкчесе Азат Идрисов, республикада сугыш ветераннарына ярдәм итүдә, Георгий тасмалары таратуда, «Үлемсез полк» составында волонтерларның башлап йөрүен һәм күпсанлы булуын әйтте.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Пешекче ул – артист та, табиб та»

МИЛЛИ АШЛАР

Атаклы аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның тууына 90 ел тулуга багышлап, «Казан» ипподромында халыкара кулинария бәйгесе уза. Анда аш-су пешерүчеләр милли ризыкларны әзерләү буенча һөнәри осталыкта ярыша. Бәйгене Казан һәм Татарстанның рестораторлар һәм отельерлар ассоциациясе, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Казан мэриясе оештырган.

Идар Мөхәммәтҗанов фотосы

Пешекче ул – артист, кунагының күңелен табу өчен, аңа, нәкъ сәхнәдәгечә, сәнгать остасы булырга туры килә. Йөзендә һәрчак елмаю. Усалланып йөрүче кеше тәмле аш пешерә белми ул.

Пешекче – табиб. Аңа кешенең сәламәтлеге тапшырылган.

Пешекче – рәссам. Аның ашы тәмле генә түгел, бик матур да булырга тиеш. Пешекче философ та, педагог та, сәгатьләр буе утлы плитә янында торучы металлург та.

Юныс ӘХМӘТҖАНОВ.

Бәйге ачылышында Юныс Әхмәтҗановның кызы – мастер-кондитер Фәридә Давыдова да бар иде.

– Бик күп бәйгеләрне күргәнем, анда катнашканым бар. Әмма монысында үзем катнашмасам да, аеруча дулкынланам. Әтием белән бик горурланам. Ул мине үз һөнәренең дәвамчысы итеп күрергә теләде. Үзем дә, улым да аның эшен дәвам итәбез. Әтинең әнисе – дәү әниебез Зәйнәп тә аш-суга бик оста булган. Әтиебез 15 яшендә завод ашханәсендә эшли башлаган. Бөтен гомере аш-су арасында узды. Авылдан авылга йөреп, татар ашлары рецептларын җыйды. Оста пешерүчеләрне бик хөрмәт итте. Ул язган китапны һәр өйдә очратырга була иде. Татар халкы элек-электән үк аш-суга оста булган, шөкер, традицияләр хәзер дә дәвам итә, – ди ул.

Татар милли аш-суының сыйфатын күтәрү, аларны популярлаштыру, әзерләү осталыгына караган идеяләрне киң җәмәгатьчелеккә таныту максатыннан оештырылган чарада Пензаның татар диаспорасы вәкилләре дә көч сынаша.

Пенза өлкәсенең «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Эльмира Васильева сүзләренчә, Татарстаннан читтә яшәсәләр дә, алар татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын сакларга тырыша.

– Татар ашлары бездә дә бик популяр. Аларны башка милләт вәкилләре дә яратып ашый. Бүген исә җюрига өй токмачы, кияү пилмәне, пәрәмәч, кабак бәлеше һәм торт пешереп күрсәтәбез. Бездә пилмәннең формасы аз гына башкачарак, ул тамчыга охшаган, – ди ул.

Бәйгедә һөнәри уку йортларында укучылар да күп иде. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты ректоры Асия Тимирясова да туризмның үсеше кайбер һөнәрләрнең популярлашуына китерүен, шул исәптән пешекче булырга теләүчеләрнең саны артуын билгеләп үтте.

– Пешекче һөнәренә кимсетеп карарга кирәкми, бу бик җаваплы һөнәр. Юныс Әхмәтҗанов та бит: «Пешекче ул – артист та, табиб та, кеше сәламәтлеге аның осталыгыннан да тора», – дип әйтә торган булган, – ди ул.

Аның сүзләрен җюри рәисе – аш-су остасы Резеда Хөсәенова да җөпләде.

– Элек пешекче һөнәрен үзләштерергә «икеле»гә-«өчле»гә укыган балалар килә иде, бүген исә башкача. Югары әзерлекле, чын пешекче булам дип килүче яшьләр күп. Берара 90нчы елларда татар ризыкларын тәкъдим итүче ресторан-кафелар да калмаган иде. Ә бүген татар өчпочмагын, чәкчәген таныту өстендә күпме эш бара. Моны күреп торган яшьләр дә һөнәри уку йортларына тартыла. Әлеге бәйгеләр нәкъ менә яшьләргә стимул булып тора, – диде.

Татарстанның рестораторлар һәм отельерлар ассоциациясе башкарма директоры Галина Шәрәфетдинова да әлеге чараны үстереп, киләчәктә аның билгеле бер көнен булдырып, вакыйга туризмы итеп күрсәтергәдер бәлки, дигән фикердә тора.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

СҮЗЕН-СҮЗГӘ

Роберт МИҢНУЛЛИН, Татарстанның халык шагыйре, «Татар гаиләсе» бөтенроссия иҗтимагый фонды рәисе:

– Халыктан күтәрелгән ике бөек кешене беләм мин, аның берсе – Әсгать Галимҗанов, икенчесе – Юныс Әхмәтҗанов. Үз өлкәсендә Юныс абыйны халык академигы дип тә әйтергә була. Татар ашларын тәртипкә китереп, китап итеп бастырып, аны халыкка җиткерде. 70-80нче елларда ул Казанда иң билгеле кеше булды. Кайсы гына газетаны ачсаң да, аның турындагы мәкаләне күреп була иде. Казанга зур кунаклар килә калса, ризыкларны аш-су остасы йөзне кызартмаслык итеп әзерли белде. Ә үзе Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның әнисе Вәсига апаның коймакларын ашарга яраткан. Юныс абый белән Нургали абый дуслар булган. Юныс абый аларга еш кунакка килә. Алдан ук шалтыратып, сезгә кунакка киләм, дип әйтә торган булган ул. Вәсига апа коймак пешереп торган. Юныс абый һәрвакыт, мин бик күп тәмле әйберләр пешерә беләм, әмма синең коймагың кебекне пешерә алганым юк әле, дип әйтә торган булган. Киләчәктә аның исемен берәр урамга биреп, бюстын да эшләтеп куярга иде. Без аны онытмаска тиеш. Әлеге уңайдан мин ике телдә «Тәмле ашлар җырчысы: Юныс Әхмәтҗанов» дигән китап чыгардым.

«Болгар радиосы» җырчыларны котлады

Узган атнаның шимбәсендә «Пирамида» күңел ачу үзәгендә «Болгар радиосы» милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы гөрләп узды. Тамашаны «Болгар радиосы»ның алты ди-джее алып барды. Алар икешәр пар булып, «яшьләр» (Илфар һәм Айсылу), «урта буын» (Рөстәм һәм Айгөл) һәм «ветераннар» (Фаил һәм Дилбәр) амплуасын башкарды.

Шамил Абдюшев фотосы

Концертның төп яңалыкларының берсе – башка җыр тамашаларыннан аермалы буларак, җыр авторларын сәхнәгә чыгарып котладылар. Фирзәр Мортазин, Айдар Тимербаев, Эльмира Җәлилова һәм башка авторлар берьюлы берничә бүләккә ия булды. Әлеге кунаклар арасында Сарманнан килгән Вәсимә Хәйруллина да бар иде. Ул иҗат иткән «Дәшмәгез» җырын Илсөя Бәдретдинова башкарды. Әлеге җырга төшерелгән клип «Иң яхшы клип» номинациясендә җиңүче дип табылды. Көй авторы Ләйсән Мәхмүтова әйтүенчә, җырның сүзләре тирән мәгънәле, зур кичерешләрне тасвирлап биргән, шуңа күрә музыкасы да үзеннән-үзе агылып киткән, көй язуы да авырлык тудырмаган.

Кунаклар дип әйткәндә, тамашада Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ренат Ибраһимов та чыгыш ясады. Сәхнәдә, өлкән яшьтәге легендар җырчылар белән беррәттән, яшь һәм урта буын артистларын да күрергә мөмкин иде. «Каеннарым» җыры белән халык мәхәббәтен казанган «Артур-Марат» дуэтын да тамашачы көчле алкышларга күмде.

– Әлеге җыр чагыштырмача иске булса да, халык аны бик яратты. Роберт Миңнуллин һәм Урал Рәшитовның иҗат җимешләрен үзебез дә аеруча яратып башкарабыз. Аннан соң концертны оештырган, аны тамашачыга тәкъдим иткән һәр кешегә зур рәхмәт. Оештыру мәсьәләсенә бер дә тел-теш тидерерлек түгел. Сәхнә бизәлеше дә, артистларны тәкъдим итү дә югары дәрәҗәдә оештырылган иде, – диде Артур Минһаҗев.

Елына бер тапкыр була һәм шундый зур масштабта үткәрелә торган тантанада продюсерлар да читтә калмады. Моңа кадәр булган фестиваль-тамашаларда аларны котлаганнары юк иде әле. Шуны искә алып, «Алтын йолдыз» сынына ия булган Рифат Фәттахов:

– Бу тарихи вакыйга, чөнки моңарчы продюсерларны гел яманлыйлар гына иде, ә бүген сәхнәдән котлыйлар, – дип шаяртып та алды.

РУХ НЫКЛЫГЫ

Көчлеләрдән курка торган чир

Елена Гредюшко фотолары

Иң кыен вакытта берәрсе, иңнәреңнән кочып: «Без бергә!» – дисә, моңарчы Каф тавы шикелле тоелган авырлыклар да бәләкәйләнеп калырга мөмкин. Чөнки кеше өчен иң куркынычы – кыенлыклар алдында ялгыз калу. «Без бергә!» – бу тылсымлы гыйбарә әллә нинди могҗизалар эшләргә сәләтле.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Онкологияне җиңгән көчле рухлы кешеләрнең оешмасы да шул тылсымлы сүз белән атала икән.

Әлеге оешманың җитәкчесе Юлия Ивашкевичка рак диагнозын болай да бик авыр чакларында – башта каенанасын, аннары үз әнисен җирләгән елны куйганнар. Аяз көнне яшен суккандай итә бу хәбәр. «Ике баламны, яраткан иремне ничек калдырырмын?» – дип кайгыра яшь ана. Һәм… авыруга бирешмәскә, яшәргә карар кыла. Әлеге максат аңа операцияләрне дә, химия терапиясен дә уңышлы узарга ярдәм итә. Кадерлеләрен борчымас өчен, хәле бераз яхшыргач бизәнеп, матур яулыклар ябып йөри башлый. Хастаханәдә ятканда, төрле халәттәге авыруларны күреп: «Бездәйләрне бергә берләштерә торган бер оешма кирәк», – дигән карарга килә. Ахирәте һәм газапташы Ольга да хуплый бу тәкъдимне. 2015 елның декабрендә әлеге хыял тормышка аша. Бүген Татарстанда һәр 40 өлкән кешенең берсенә шундый куркыныч диагноз куелган. Димәк, бу проблема шәхси генә түгел, ә илкүләмгә әйләнеп бара.

Февраль башында Халыкара онкологиягә каршы көрәш көне билгеләп үтелде.

– Мин көрәш дигән сүзне бик яратып бетермим, – ди Юля. – Ул сугыш мәйданын хәтерләтә. Ә безнең һәр көнгә сөенеп, әйләнә-тирәбездәгеләрне шатландырып, игелек кылып, көрәшмичә генә яшисебез килә.

Әйе, «без бергә»леләрнең үз фәлсәфәләре: «Кешегә ярдәм иткәндә, үзеңә дә булышасың!»

Мин аларны күбрәк белергә, аңларга теләп, «ВКонтакте» челтәрендәге төркемнәренә дә кереп карадым. Бер-берсенең күңелен күтәрергә тырышуларына, тормышка мәхәббәт хисләренең чиксезлегенә шаккаттым. Һәр язмада, һәр җөмләдә, һәр фотосурәттә бу хисләр. Әйе, язмышларына үпкәләп, елап утыра торганнардан түгел алар: бассейнга, йогага да йөриләр, рәсем ясап та дәваланалар. Ярдәмгә мохтаҗ балалар янында да булалар. Ә бит бер карасаң, үзләренең дә диагнозлары бик катлаулы: яман чир кайсының умыртка баганасында, кайсының бавырына үрмәләгән. Бу мәкерле чир инде бетте дигәндә дә яңадан баш калкытырга сәләтле, ә җиңеләсе килми. Аларның да җиңәсе килә. Казанлылардан үрнәк алып, Тамбовта да шундый оешма төзелеп ята икән. Иң мөһиме шунда: анда да әлеге оешманы шулай татарча атаганнар. Ике оешма вәкилләре тиздән очрашырга ниятләп тора.

13 февраль көнне «Ак барс» концертлар залында, Бөтендөнья онкология авырулары көне уңаеннан әлеге оешмага ярдәм йөзеннән, «Яшәү көе» дип аталган хәйрия чарасы узды. Анда бу көчле рухлы ханым һәм әфәнделәр белән кабаттан аралаштым. Оешманың яңа әгъзалары белән дә таныштым. Әнисә, Катя, Оля, Гөлфизә… Концертлар залы фойесында һәркем теләгән эше белән шөгыльләнә. Кемдер рәсем ясый, кемдер белгеч-визажистлар янында. «Без бергә!» оешмасына йөрүче ханым-апалар тәмле сумсалар, печеньелар пешереп килгәннәр, кунакларны чәй белән сыйлыйлар. Әлеге чара өчен махсус ясалган «Теләкләр агачы» тасмалар белән бизәлергә өлгергән. Аларның барысында да бер теләк – исән-сау булып, якыннарын сөендереп озын-озак яшәү.

Концерт искиткеч булды. Зал тутырып килгән тамашачы танылган артистлар һәм коллективлар белән бергә опера, рок, лирик җырлар тыңлап кына калмады, файдалы киңәшләр дә алды. Чараның иң югары ноктасы Республика онкология диспансерының баш табибы Илдар Хәйруллин чыгышы булгандыр. Кайчандыр үзе дә шушы яман чир тырнагына эләккән табиб хәзер гомерен авыруларга ярдәм итеп үткәрә. Үзенең уй-теләкләрен гитарада уйнап җырлап биргәч, зал аны дәррәү килеп алкышларга күмде.

Рак – хөкем карары түгел, ул бит дошман пулясы төсле бәреп екмый, яшәргә күпмедер вакыт калдыра. Ә ул вакытны үзеңә дә, кешеләргә дә шатлык китерерлек итеп мәгънәле, үкенмәслек итеп үткәрергә уйлый яңа танышларым. Планнары да, хыяллары да зурдан аларның. Исән генә булсыннар, берүк!

Билгесез батырлар эзеннән

«Сугыш аның иң соңгы солдаты күмелгәндә генә тәмамлана», – диләр. Бик кызганыч, алай дисәң, Бөек Ватан сугышы да тәмамланмаган әле: һәлак булган бик күп сугышчыларының җәсәдләре әле бүген дә, җиде дистә елдан соң да, җир куенына иңдерелүне көтеп ята.

Бу изге эшкә узган гасырның 70нче елларында ук яшь буынның булышырга алынуы сөенечле хәл булып тарихка кереп калды. Казан дәүләт университетында оешкан «Кар десанты» отряды бу хәрәкәтнең башында торып, күп кенә хәбәрсез югалган сугышчыларның исемнәрен туганнарына кайтаруда һәм аларның җәсәден данлап җирләүдә әйтеп бетермәслек зур эш алып барды, «Хәтер» китабының яңа битләре нәкъ менә аларның фидакарьлеге нәтиҗәсендә язылды. Аннары алар үрнәгенә башка шәһәрләрдән дә студентлар кушылып, сугыш барган урыннарда каникул вакытларында эзләнү эшләре алып бара башладылар. Билгесез солдатларның исемлеген киметүдә аларның роле гаять зур. 27 февраль-1 март көннәрендә эзләнү отрядларының беренче Бөтенроссия слетының Казанда узуы да шуның белән аңлатыла. Республикабыз башкаласы Казанга илебезнең 84 махсус урта һәм югары уку йортларыннан сугышның билгесез батырларына битараф булмаган егетләр һәм кызлар килде. Алар үзләрен борчыган мәсьәләләрне уртага салып киңәшләшеп, хәл итәр, эзләнү эшен тагын да киңәйтү юлларын табар өчен җыелдылар башкалабызга. Слетта эзләнү отрядлары булган Казан вузларының җитәкчеләре, бу эшнең башында торган беренче эзтабарлар белән кызыклы очрашулар да көтелә. Болар барысы да Бөек Ватан сугышының калын томының соңгы битен ябып, аңа нокта кую көнен якынайтыр дип ышана оештыручылар.

Ренат Ибраһимовның тагын бер сәләте ачылды

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ренат Ибраһимовның иҗат кичәсе Милли китапханәдә узуы очраклы түгел. Аның яңа гына дөнья күргән үзе язган «Избранное» дигән китабы тәкъдир ителде. Китапны җырчы үзенең быел булачак 70 яшьлек юбилеена багышлаган.

Ул иң элек үзенең кызы туу шатлыгы белән уртаклашты. Аңа Мәрьям исеме кушканнар икән.

– Китапны моннан ике ел элек яза башлаган идем. 50 ел иҗат юлым сизелми дә үтеп киткән. Казанда укыган, опера һәм балет театрында, филармониядә, «Сәфәр» иҗат үзәгендә, аннары Мәскәүдә радиода, телевидениедә эшләгән елларым артта калды. Үземнең хатирәләремне яңартып, аны укучыларга тәкъдим итәсем килде. Балачагым, яшьлек елларым, эшләгәндә очраган кешеләр турында истәлекләрем белән уртаклаштым. Китапның үз укуымда аудиодискы да (ул дүрт сәгатьлек) чыкты, – дип сөйләде Ренат Ибраһимов.

Ул тормышта үзенә яшәү серләре булып саналган, Коръәннән алынган гыйбарәләрне дә китабыннан укып күрсәтте. Җыентыкта җырчы язган шигырьләр, үзе ясаган рәсемнәр урын алган.

Кичәдә Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев тә катнашты.

– Ренат Ибраһимов – Татарстан, Россия тарихына кергән кеше. 1972 елда композитор Рәшит Абдуллин соравы буенча, мин «Төсле җыр» дигән шигырь яздым. Аны Ренат Ибраһимов башкарды. Аннары мин Ренатның рәссам икәнен дә белә башладым. Әмма аның язучы-журналист икәнен белми идем. Китабын бер утыруда укып чыктым. Татар тарихы сыйган ул китапка. Ул үзенә күрә энциклопедия. Аны һәр мәктәп китапханәсендә булырга тиеш дип саныйм. Соңгы вакытта татарларны София Гобәйдуллина, Рудольф Нуриев, Ренат Ибраһимов аша беләләр, – диде ул һәм җырчыга китаплар бүләк итте.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

«Яңа Гасыр» – 21нче төймәдә

«Яңа Гасыр» телеканалы, федераль конкурста җиңеп, хаклы-лаеклы рәвештә 21нче төймәне алды.

Исегезгә төшерик, моңа кадәр мультиплекска бәйле рәвештә милли телеканал язмышы кыл өстендә иде. «Мәҗбүри рәвештә» статусында бары тик икенче мультиплекска кертелгән федераль каналлар гына исәпләнде. Бары тик Россия Президенты Владимир Путин инициатив төркем тәкъдимен яклагач кына вазгыять үзгәрде. Төбәк каналларына 21нче төймә һәм «Региональ мәҗбүри гомумкулланылыш телеканалы» статусы бирелде. Бу статуска дәгъва кылу өчен, телеканал үз тапшыруларының 75 процентын милли җирлектә әзерләргә тиеш һәм аларны республиканың яртыдан ким булмаган өлешендә трансляцияләргә бурычлы.

Узган атнада Мәскәүдә шул уңайдан конкурс комиссиясе утырышы узды. Идел буе федераль округының 14 субъектыннан килгән гаризалар арасында безнең республиканы тәкъдим иткән «Яңа Гасыр» телеканалы җиңүче дип танылды.

– Шул рәвешле, «Яңа Гасыр» телеканалы Татарстан Республикасы территориясендәге барлык элемтә челтәрләрендә 21нче урынны ала, ә бу уңыш безнең телеканалны эзләү эшен бермә-бер җиңеләйтә. Барлык операторларга, конкурс комиссиясе утырышының нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң, безнең телеканалны 21нче төймәдә урнаштырырга дигән хатлар таратыла, – диде «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директорының беренче урынбасары – икътисад директоры Илшат Сафиуллин.

ТОРМЫШ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ

Менә шулай...

Автовокзалдан такси белән редакциягә кайтам. Таксист, 40ның өстендәге ир, алдыбызга терәлеп диярлек бер машина кергәч, сүгенү сүзләре кулланмыйча гына шундый итеп әйтеп куйды – бала тәннәре чыгарлык булды. Аннары рөхсәт сорап, тәмәке кабызды. «Ташлап карагыгыз юкмы?» – дидем мин, үземнең дә шул әшәке нәрсәне ташлый алмавымны искә төшереп. «Уразага кергәч ташлыйм, – диде таксист, бик ышанычлы гына. – Ул чакта авыр булмый».

Киттек. Казан «бөкеләре» сөйләшергә мөмкинлек бирә ул. Таксист миңа карамыйча гына ачылып китте:

– Әлмәттән мин. 42 яшемнең 35 елын тартам. Шулай үстек бит инде. Әни укытучы иде. Мөстәкыйльлек кирәген аңлагандыр, җиде-сигез яшемдә үк өлкәнрәк малайлар белән төнгә балыкка җибәрә иде. 90нчы елларның бөтен дәһшәтен үттем. Сугыштым да, талаштым да. Төрлесе булды. Төрмәдән чак калдым, барлык дусларым да диярлек утырып чыкты. Күбесе җир куенында инде. Ә мин менә исән. Эчтем, яшермим дә. Әнигә 80 яшь тулгач, эчүемне ташларга булдым. Әнине бик нык яратканмын икән. Шулкадәр юксынам! Бер генә тапкыр булса да сөйләшеп утырасы иде, бер генә кочаклыйсы иде үзен. Ташладым аракыны, айлар буе әчеп ятулар бетте. Әни шул ук елны вафат булды. Яшермим, вакыт-вакыт үтерeп «саласы» килә. Тик эчмим – ярамый. Менә хәзер тәмәке тартуны да ташларга уйлыйм. Әле исәнлек бар, яши башлаган гына кебек. Эчү аркасында аерылдым инде, үзем генә яшәргә өйрәндем. Килеп-китеп йөрүче хатын-кызлар бар, тик берсе дә ышаныч гаиләкорырлык түгел кебек. Бәлки мин ялгыз яшәргә өйрәнеп беткәнмендер. Эчмәгәч, рәхәт бит. Баш авыртмый, акча бар...

Таксист ир, тәмәкене ташлаячагы турында сөйләп, күңелне кымырҗытты. Шундый ышанычка нинди сәбәп барлыгын сорадым.

– Әни вафат. Әнкәнем, тартканым өчен аңардан гафу үтенә алмыйм. Менә шул гына, – диде ул, бераз уйланып баргач. – Брат, исән булса, мөмкинлегең булу белән, әниең янына кайт, безне бу җирдә яраткан бердәнбер кешеләр – әниләр ул...

Таксидан төшеп калуга ук, урам уртасында баскан килеш, әнигә шалтыраттым. 1 марттан тәмәкене дә ташлаячагым турында әйтеп шатландырасым килде үзен.

Илфак ШИҺАПОВ.

Бүгенге көндә татар дөньясы кайсы өлкәгә караган терминнарга кытлык кичерә? Соңгы елларда терминология өлкәсендә нинди эшләр башкарыла? Туган тел көне уңаеннан «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы уздырган матбугат конференциясендә сүз, нигездә, шул хакта барды.

«Үз телебездәге терминнар аз»

– Татар телендәге терминологиянең төп проблемасы – телебезнең табигый закончалыгына туры килгән, шушы нигездә үскән һәм килеп чыгышы ягыннан төрки-татар тамырлы терминнарның аз булуы. Ясалмалылык килеп керү табигыйлекне җимерә, чөнки без бүген Европадан һәм рус теленнән терминнар алу белән мавыгабыз, – диде Казан федераль университетының татар теле белеме кафедрасы җитәкчесе Гөлшат Галиуллина.

Гыйлем.татар порталының баш мөхәррире Айдар Шәйхин исә Гөлшат Галиуллинаның: «Телебезгә нигезләнеп барлыкка килгән терминнар аз», – диюенә үзенчә җавап бирергә тырышты. Аның фикеренчә, төп проблема – татар телендә фәнни хезмәтләр язылмавында. «Иң мөһиме – алтын урталыкны югалтмау. Укучыларыбызның татарча терминнарны кабул итәргә әзер булмавы да бар. Без аларны акрынлап ияләштерергә тиеш», – диде ул. Христиан һәм мөселман дини терминнары мисалында терминнарның бер өлкәдән икенчесенә күчү мөмкинлегенә дә тукталып үтте Айдар Шәйхин.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты доценты, университетның татар телендә укыту буенча методик кабинет мөдире Рәшит Шакирҗанов сүзне моннан 25 ел элек ничек итеп институтта беренчеләрдән булып техник фәннәрне татарча укыта башлаулары, 17 ел дәвамында чыккан «Тел һәм фән» журналында терминнарның чарлана, шомара баруына тукталды. Нефть тармагына, төзелешкә һ.б. өлкәләргә караган терминнар тупланган сүзлекләр чыгу да күзгә күренгән җитди эшләр булара аталды.

– Бүген бездә сүзлек төзү ниндидер бер уенга әйләнде. Һәрбер кеше бер юнәлешне ала да сүзлек төзи һәм каяндыр акча юллап табып бастырып чыгара. Әмма бу ул үзе теләгәнчә генә килеп чыга. Куллапыш хакында уйламыйлар. Ә бит ул бик җитди мәсьәлә, – ди Рәшит әфәнде.

Матбугат киңәшмәсендә катнашкан Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы фәнни-техник документация бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Җәлил Мотыйгуллин бераз тынычланырга урын калдырды. Аның:

– Галимнәр өчен көндәлек эш булган әйберне проблема итмик. Әгәр дә проблема бар икән, аны бергәләшеп чишик. Монда массакүләм мәгълүмат чараларының роле зур. Әгәр сез булмаган проблеманы проблема дип бирсәгез, ул халыкта борчу тудырачак, – дигән сүзләре проблемадан качу өчен генә әйтелмәде, билгеле. Кайда проблема бар, кайда юк икәнне ул үзе дә яхшы белә.

– Нинди дә булса сүзне, әйдәгез, русча гына калдырыйк дип әйтү – бу әле проблема түгел. Татар теленә тәрҗемәне бетерик дию – менә монысы проблема. Тәрҗемә итү – байлык ул. Әгәр әлеге байлыктан баш тартабыз икән, монысы беткә үч итеп, тунны утка ягу булачак. Гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыра барып, теләсә нинди фәнне үз телебездә теләсә нинди терминнарны кулланып укыта алабыз, – диде Җәлил Мотыйгуллин.

Сөйләшүдә катнашучылар терминологиягә төрле яклап килделәр. Шуңа да Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге җитәкчесе Айнур Тимерханов: «Мондый сөйләшүне кварталга бер уздырып торырга киңәш итәр идем», – дип юкка гына әйтмәде инде. Ул үзе дә проблеманы төрле аспекттан (дәүләт, галимнәр, кулланыш) чыгып карады. Әгәр дә тел кулланышта, әгәр дә ул җанлы организм икән, анда һәрдаим үзгәрешләр булып торачак, бу – табигый, дигән фикердә ул.

Уенны парсыз калган уенчы дәвам итә...

Ни иканен беләсеңме аулак өйнең?
Беләсеңме бер нотасын
безнең көйнең?
Белмәгәчтен, бар, кайтып кит,
Җанкисәгем,
Килсен монда йә аниең, йә әбиең...

tatar-almetteatr.ru

СӘХНӘДӘ – ТОРМЫШ

Әлмәт Татар дәүләт драма театрының Равил Сабыр әсәре буенча куелган «Сигезле бию» спектаклен карагач, үземне Туфан абый Миңнуллинның әлеге робагыендагы аулак өйдән куып кайтарылган теге «Җанкисәгем» итеп хис иттем. «Сигезле»нең ничек биелүен белмим икән.

Әсәрнең дә, спектакльнең дә фольклорга катнашы юк, әлбәттә. Ялгыз язмышлар турында бәян бу. Әлеге тема гаять популяр, һәрчак актуаль, күздән яшь чыгарырлык – нечкә күңелле тамашачы күңеле өчен чак кына. Трагизм да, комизм да җитәрлек бу әсәрдә. Тик әсәр исеменең җисеменә тәңгәллеген эзләп, биюнең нигезенә нинди фикер салынганын аңлау кирәк, әсәргә исем яңгыравыклылыгы өчен генә куелмагандыр.

«Сигезле уен»ы турында фольклорчы галимнәр болай язганнар: «Уенчылар ике рәткә бүленеп кара-каршы басалар. Парсыз калган кеше, сигезле ясап, гармун көенә бии-бии, уенчыларны әйләнә. Гармун туктагач, кем янында туктаса, шуның белән парлап бииләр. Уенны парсыз калган уенчы дәвам итә».

Равил Сабыр да, язмышларын язарга алынган героиняларының төрле сәбәпләр белән ялгыз гомер кичерәчәкләрен аңласа да, алардан барыбер уенны – пар эзләү, яр көтү, парлылык хакында хыяллану уенын дәвам иттерә. Героинялар – сигез. Сигез героиняга бер герой да юк. Бердәнбер «герой» – спектакльнең башыннан ук сәхнәдәге тамашаны күзәтеп, өстә колосникларда эленеп торган ират пәлтәсе. Спектакльдә исемнәре гел телгә алынып торган ир-атларның да «пәлтә эчләре»ндә әллә ни мактаныр нәрсәләре юк кебек. Икейөзле уенчы, Ләйләнең (Рәзинә Хәкимова, Ләйсән Нуриева) мәхәббәтен «уңышлы партия» кәләшкә алмаштырган Робертның калебе чистамы? Юк бит. Ләйләнең фатирдашы, бераз көлке һәм тилемсә, ачу чыгаргыч дәрәҗәдә гади Сәйдә (Татарстанның атказанган артисты Гөлнара Кәшипова) туктаусыз телгә алган Сәет, шулай ук, инде картаеп барса да, игезәге Сәйдәдән башка тәмәке дә сайлый белмәүче бер мәхлук лабаса.

Мәхәббәт көтеп үрсәләнгән Ләйлә, тынгысыз Сәйдә, гомере буе трамвай йөртеп, үзе дә рельслар кебек тимер күңеллегә әверелгән, кызы белән уртак тел таба алмый яшәүче кырыс ана Люция (Зөлфия Газизова), ялгызлыгын уртаклашыр өчен икенче бер ялгызны гасабиланып эзләүче Мәрьям (Татарстанның атказанган артисты Асия Харисова), кызына бәхет «аксессуары» итеп алынган фатирны, кызын кияве ташлап чыгып киткәч, «сдавать итеп» көн күрүче Зөһрә (Римма Гайсина), ике хәйлә тозагы – йоклар өчен яхшы, яшәр өчен җәһәннәм кадрлары Эля (Алсу Сибгатуллина) белән Гуля (Ләйсән Игошина, Сиринә Мифтахова) – һәрберсе аерым холыклы, ләкин аңлаешлы образлар. Ә Нурлыбәян әби (Татарстанның атказанган артисты Гөлнара Вәлиева) нишли бу әсәрдә? Аның язмышы, ул күргән, ул кичергәннәр алдында яр көтеп, ялгызлыкка уфтанып утырулар артык баналь түгелме? Блокаданың барлык михнәтләрен, ачлыктан интеккәннәрнең урамда егылып яткан яһүд хатынының итле җирен кисеп алып киткәннәрен күргән кеше психологиясе нинди булырга тиеш? Нурлыбәян әби бу тарихка авторның запасында шундый тетрәндергеч вакыйга булу сәбәпле генә кергәндер. Аның тарихы аерым трагик әсәргә дә нигез була алыр иде. Хәзерге замана да чуар бит, төрле фаҗигаләр күреп тетрәнүләр күп. Мәхәббәтне югалту гынамы сиңа...

Спектакльне сәхнәгә куйган режиссер Булат Бәдриевнең театр дөньясындагы тормышын, төрледән-төрле «күчеш»ләрен күзәтеп барырга тырышам мин. Ул – театр баласы, Минзәлә театрының данлыклы артистлары Илүсә апа һәм Фәез абый Бәдриевләрнең уллары. Эшен Минзәлә театрында, экспериментларга кыю алынучы кызыклы режиссер булып башлады, аннан Чаллы драма театрына күченде, инде хәзер Оренбург театрында.

Аның Мансур Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Яратылыш» спектаклен моннан күп еллар элек Минзәләгә барып караган һәм халык телендә «балаитәкле театр» дип йөртелгән театрның кызыклы экспериментларга да кыюлыгы җитүен күреп куанган идем. «Сигезле бию» нәкъ менә эксперимент, яңалык таләп итүче әсәр, минемчә. Булат аны тиешле дәрәҗәгә җиткереп куярга һәм үзенә дә талантлы режиссер исемен кире кайтарырга тиеш иде кебек...

Спектакльне Әлмәт бомонды, шәһәрнең киң җәмәгатьчелеге яраткан, яхшы кабул иткән, диләр. Мин дә кабул иттем. Дәрес, бәлки әлеге куелыштан күбрәк көткәнмендер.

Әлмәт театрында яхшы артистлар кытлыгы беркайчан да булмагандыр кебек, ә менә алар өчен репертуар кытлыгы һәрчак бар һәм бу бер театрның гына да бәласе түгел. Берьюлы сигез актрисаны рольле иткән авторга да, театрга да бу очракта рәхмәт әйтү кирәк. Спектакльне Казанга зур гастрольгә алып килергә шикләнмәгән өчен, театр җитәкчелегенә дә респект! Башкала гастрольләре – Кече театрлар өчен бәйрәм ул. Ә бәйрәмдә репертуарны тартып баручылар да, төрле сәбәпләр аркасында аз уйнаучылар да катнашырга хокуклы.

Бу килүендә Әлмәт театры, гомумән, репертуарда жанр төрлелеге белән гаҗәпләндерде. Заллары да тулы иде, язучылар, театр әһелләре, журналистлар игътибары да җитәрлек булды. Фестивальләрдән кайтып кермәгән һәм барган бер фестивальдә лаеклы бәя алган театр өчен табигый игътибар инде бу.

PS. «Килсен монда йә аниең, йә әбиең» дигәннән, театр Аяз абый Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Кар астында кайнар чишмә» спектаклен дә алып килгән иде. (Әлмәт театрының бу килүендә минем бәхеткә шушы ике спектакле генә тиде.) Традицион, «мөгез чыгармый» гына куелган спектакль. Сюжет – бәхетле кавышу белән тәмамланган көтелмәгән мәхәббәт матавыгы, «балалар» һәм аталар» проблемасының матур чишелеше. Ә андагы репликалар, диалоглар, Аяз абыйның гаҗәеп җөмләләре. Ләкин... без күптәннән алай сөйләшмибез шул инде. Без – өзек-төтек сөйләм, ашык-пошык әңгәмәләр заманы геройлары. Әбиләр, әниләр теленең «тональносте» безнең өчен югарымы, түбәнме?

Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.

МАЙ ЧАБУ

Аккош күле буенда узган быелгы «Май чабу» бәйрәме, аның төп атрибуты – кояш символы булган кайнар коймаклары, күңелле уеннары, гөрләп торган сәүдә рәтләре белән генә түгел, ә бәйрәмне тагын да ямьләндереп җибәргән «На-на» төркеменең чыгышы белән дә истә калачак.

Борынгыдан, мәҗүсилек чорыннан ук килгән бу бәйрәмдә табигатьне уяту өчен барысы да эшләнә. Быелгысы да искәрмә булмады, Май чабу йоласы, һәрвакыттагыча, карачкы яндыру белән тәмамланды.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com
Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 6219.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 681. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы